КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 22

«Нурлат муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт бюджет социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән «Нурлат муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе төзү турында

«Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрен үзгәртү һәм ликвидацияләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре мөлкәтен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Нурлат муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт бюджет социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән «Нурлат муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе (алга таба - автоном учреждение) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Автоном учреждение эшчәнлегенең төп - максаты гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

автоном учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

60 көн эчендә:

автоном учреждение уставын расларга һәм аны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

автоном учреждениенең күзәтү советы составын расларга;

ел саен автоном учреждение өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга;

4. Автоном учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законда әлеге максатларга каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына автоном учреждениенең уставын дәүләт теркәвенә алганнан һәм автоном учреждениенең күзәтү советы составы расланганнан соң 20 көн эчендә автоном учреждениегә Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Нурлат шәһәре, Пушкин урамы, 46 йорт адресы буенча урнашкан, 16:50:010141:51 кадастр номерлы җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы бюджетының берләштерелгән бюджет язуыны «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча автоном учреждение тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанс тәэмин итү чыгымнары өлешендә үзгәрешләр кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин